ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЯХШЫЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам,18 нче йорт.
Тел.885552 3-44-45.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

423765, с. Верхнее Яхшеево,
ул. Новая, дом 18.
Тел. 885552 3-44-45.
E-mail vyah.akt@yandex.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«17» января 2020 г. № 3

**2020 елга Хатын-кызлар советының эш планын раслау турында**

Хокук саклау органнарына һәм башка дәүләт органнарына хокук тәртибен тәэмин итүдә ярдәм итү, социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүгә киң җәмәгатьчелекне җәлеп итү, хатын-кызларның, гаиләнең, ананың һәм балачакның хәлен яхшырту, хатын-кызларның җәмәгать эшләрендә актив катнашуы өчен иң уңай шартлар тудыру максатыннан чыгып

КАРАР БИРӘМ:

1. Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге территориясендә 2020 елга хатын-кызлар советының чаралар планын расларга (№1 кушымта).
2. Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие һәм учреждение җитәкчеләренә хатын-кызлар советы эшчәнлегенә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Югары Яхшый авыл җирлеге бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Югары Яхшый авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Җ. Г. Зиннатуллина

Югары Яхшый авыл җирлеге
башкарма Комитеты

17.01.2020 ел № 3 карарына
кушымта

Югары Яхшый авыл җирлеге хатын-кызлар Советының 2020нче елга эш планы

| № | Мероприятия | Дата проведения | Ответственные |
|---|---|---|---|
| 1. | Җирлектә хатын-кызлар советы утырышы үткәрү һәм 2020 елга эш планын раслау | Квартал саен | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 2. | Чараларда катнашу:<br>-Республика көне уңаеннан<br>-Халыкара хатын-кызлар көне<br>-гаилә көне<br>-балаларны яклау көне<br>-өлкәннәр көне уңаеннан<br>-авыл җирлекләре арасында Спартакиада<br>-Әниләр көне<br>-Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү<br>-милли бәйрәм-Сабантуй<br>-"Ягез әле, кызлар, әниләр һәм әбиләр!»<br>-үзешчән сәнгать смотры | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 3. | Югары Яхшый авыл җирлегенең хатын-кызлар советы эшчәнлеге папкасын тулыландыру | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 4. | Хатын-кызлар советы эшчәнлегенә анализ ясарга, нәтиҗәләр буенча аны камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләргә | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 5. | Участок уполномоченныйлары һәм ПДН инспекторлары белән берлектә, социаль иминлекнең сәбәпләрен ачыклау максатыннан, хәмердән явызларча файдаланучы гаиләләрдә балигъ булмаган хокук бозучылар булган гаиләләрдә йөрергә; | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 6. | Җәмгыятьнең аерым игътибарына мохтаҗ булган хатын-кызларны исәпкә алу<br>(күп балалы, ялгыз аналар, өлкән яшьтәге ялгызлар, эчүчеләр һ. б.)) | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 7. | Хатын-кызларга ярдәм итүгә мәгълүмати-белешмә, методик материаллар әзерләү | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 8. | «Беренче сыйныфка баручы | Август | Хатын-кызлар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | балаларның әниләре белән "беренче сыйныф укучысының адаптациясендә гаиләнең роле" темасына очрашу оештыру | | Советы рәисе, членнары. |
| 9. | Сәламәтлек саклау органнары белән берлектә иминлекнең иртә стадиясендәге гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны ачыкларга. Өлеге гражданнар белән индивидуаль-профилактик эш алып бару | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 10. | Эчке эшләр бүлеге һәм җирлекнең Җәмәгатьчелек советы белән берлектә законсыз хәмер, ялган алкогольле продукция белән сәүдә итү урыннарын ачыклау һәм нейтральләштерү буенча рейдлар үткәрергә | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 11. | Авыл җәмәгатьчелеге Советы белән берлектә эчкечелек, наркомания, тәмәке тарту һәм башка хокук бозуларны кисәтү максатыннан яшьләр күпләп җыела торган урыннарда рейдлар үткәрергә | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |
| 12. | Яшьләр һәм башка затлар тарафыннан хокук бозуларны булдырмау максатыннан массакүләм чараларда дежурлыкларда катнашу | Ел дәвамында | Хатын-кызлар Советы рәисе, членнары. |